Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге составына керүче Байлар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«23» ноябрь 2024 ел №9

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Байлар торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 23 ноябрендә узган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Байлар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, махсус хәрби операциядә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыннан, балаларыннан), Россия Армиясенә хәрби хезмәткә алынучылардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү сез ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Байлар торак пунктында Октябрь урамындагы юлны норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш салу, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Байлар торак пунктында җирлек юлларын карап тоту (грейдерлау һәм юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)?» - соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 315 граждан кертелде;

тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 168 кеше, бу 53,3% тәшкил итә.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«Риза» позициясе өчен 165 граждан тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен 3 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Байлар торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын узган һәм аның нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

1. Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Байлар торак пунктында гражданнар җыенының:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Байлар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол

хатыннарыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, махсус хәрби операциядә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыннан, балаларыннан), Россия Армиясенә хәрби хезмәткә алынучылардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү сез ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Байлар торак пунктында Октябрь урамындагы юлны норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш салу, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Байлар торак пунктында җирлек юлларын карап тоту (грейдерлау һәм юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)?» - сораулары буенча гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова